ГЛАВА
Новобизякинского сельского поселения
Агрызского муниципального района
Республики Татарстан

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Яңа Бәзәкә авыл җирлеге
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

13.11.20232 № 1

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм кулану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Яңа Бәзәкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Яңа Варклед-Авыл торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Яңа Бәзәкә авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Яңа Бәзәкә авыл җирлеге башлыгы к а р а р и т т е:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Яңа Бәзәкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Варклед-Авыл торак пунктында гражданнардан үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2023 елның 24 ноябрендә 09 сәг 00 мин билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны түбәндәгечә расларга: «2024 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Яңа Бәзәкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Варклед-Авыл торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә, I төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән өлкән гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, ирекләреннән мәхрүм итү урыннарында торучы затлардан һәм Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәткә чакырылган затлардан тыш, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны (хәрби хезмәткәрләрне, мобилизацияләнгән, ирекле киткән) һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатыннарын, балигъ булмаган балаларын) түләүдән азат итү һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен файдалануга ризамы:

1. Урам яктырту челтәрләрен ремонтлау (электротоварлар сатып алу һәм лампаларны, фонарьларны алыштыру һәм хезмәт килешүе буенча электрикка хезмәт хакы түләү).

2. Су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алу, аларны чистарту, транспортировкалау һәм су агызу системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм башка инженер корылмаларын төзү һәм ремонтлау (су белән тәэмин итү системалары өчен материаллар һәм электр товарлары сатып алу).

3. Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (Варклед-Авыл торак пункты янәшәсендәге урман буендагы җир кишәрлекләре янәшәсендәге урыннарда үлән чабу һәм янгынга каршы минерализацияләнгән полосаларны сөрү һәм ягулы-майлау материаллары сатып алу).

4. Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (үлән чабу һәм торак пункт урамнарын кардан чистарту)

5. Халыкның күпләп ял итү урыннарын төзү, ремонтлау һәм алар тирәсендәге территорияләрне төзекләндерү (МТЗ-82 тракторын карап тоту һәм хезмәт күрсәтү ( запас частьләр, дизель ягулыгы алу һәм штаттан тыш хезмәткәргә хезмәт килешүе буенча хезмәт хакын түләү, трактор өчен өстәмә асылма җиһазлар сатып алу); кешеләрнең тормышына һәм сәламәтлегенә куркыныч янаучы авария һәм коры яшеллек утыртмаларын кисү).

6. Традицион җирләү урыннарын ремонтлау, коймалар төзү, төзекләндерү (зиратның хуҗалык блогын ремонтлау).

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Гражданнар җыенын Татарстан Республикасы, Әгерҗе районы, Варклед-Авыл, Колхоз урамы, 1 нче йорт янындагы мәйданчыкта үткәрергә.

4. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Яңа Бәзәкә авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештыруны һәм үткәрүне йөкләргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Яңа Бәзәкә авыл җирлегенең мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Авыл җирлеге башлыгы М.С. Салихов